# ТУГАН КӨНЕГЕЗ БЕЛӘН, ЗӘЙНАК АБЫЙ.

Тормышымның иң матур чорларына кайтып, мәктәп еллары хатирәләрен яңартырга булдым әле. Мин үземнең укытучыларымны һәрвакыт иң хөрмәтле, иң якын кешеләрем дип исемә төшерәм. Алар арасында Зәйнак абый аерым урын алып тора. Ул безне физкультура һәм хезмәт дәресләреннән укытты. Бигрәк тә бу предметлар укытучыдан нык тәртип урнаштыруны таләп итә. Зәйнак абыйның хәрби хезмәттә булган офицер икәнен белә идек. Димәк, тәртип тә югары дәрәҗәдә булачагын аңлый идек.

Дөресен әйтергә кирәк, физкультурадан мин бик курка идем. Сәламәтлек йомшаграк булгангамы – белмим. Ул чагында спорт костюмнары бик юк. Чалбар кисәк тә, өстеннән күлмәк киеп куя идек. Чалбар белән йөрү кызларга оят кебек тоела. Аның костюмы да хәзерге матур, җиңел костюмнар түгел, фланельдан тегелгән калын, киң, зур, җылы, кыш көне кия торган иде. “Кәҗә”(козел) дигән спорт инвентаре аша сикереп чыгу үзе бер газап. Инде сикереп кенә чыктым дигәндә итәк шул “кәҗә”нең башына эләгә дә я барып төшәсең, я шул “кәҗә”гә атланып каласың. Зәйнак абый нишләптер баштарак итәкләрне салырга мәҗбүр итми иде. Соңрак өлкән классларда итәк кисәң дәрескә кертми башлады, киреләнсәң, икеле куя. Юкса үзебезгә чалбар белән җайлырак бит инде. Тагын бер күбебез булдыра алмый торган спорт инвентаре – канатка менү иде. Малайлар булдыра, ә без кызларның кулларының көче җитми. Ә менә брусьяда күнегүләр ясарга ярата идем. Зәйнак абыйның шул гадәте бар: һәр күнегүне ахыргача эшләтмичә туктамый иде. Хәрбиләрчә русчалап әйтсәң: “Не можешь – научим, не хочешь – заставим” дигән кебек була инде.

Бер вакыйга исемдә. Район күләмендә безнең мәктәптә чаңгы ярышы булырга тиеш иде. Мин җиденче класста укыйм. Зәйнак абый мине ярышка катнашучылар исемлегенә кертте. Минем котым алынды. Нинди ярыш инде! Мин үземне иң слабый укучы дип йөрим бит. Катнаштырмавын сорап та карадым, елап та алдым, кая ул! Ярыш көне килеп җитте. Итеккә чаңгыларны ныгытып куйдым, үзем, русча әйтсәк, в обморочном состоянии, киттем башкаларга ияреп. Миннән дә йомшаграклар да булганмы – белмим: әле берсен, әле икенчесен үтеп киткәләп, соңгы сулышымда килеп җиттем дә авам дигәндә Зәйнак абый тотып калды, кайнар чәй эчертеп, көч бирде.

Икенчеме, өченчеме килгәнмен, онытканмын инде. “Менә бит, булдырдың,” - ди.

Хәзер хезмәт дәресләренә күчәм. Без укыганда хезмәтне кызлар да, малайлар да бергә өйрәнә иде. 5-6 классларда Зәйнак абый безне столяр эшенә өйрәтте. Балта, пычкы, чүкеч, карга борыны кебек эш коралларын белә идек инде. Хәтердә, без табуретка ясадык. Бер малай, бер кыз бер урындык ясарга тиеш. Менә шунда әллә нинди кораллар белән танышып кына калмадык, алар белән эшләргә дә өйрәндек. Иремнең әтисе алтын куллы кеше иде, һәрвакыт мастерскоенда нәрсәдер эшли, кораллары да бик күп. Мин аңа булышырга уйладым. Коралларның исемнәре белән сорыйм. “Син боларны каян беләсең?”- ди. Мин әйтәм: “Хезмәт укытучысы өйрәтте,”- дим. Бу миннән экзамен алырга тотынды. Мин тезеп киттем: рубанок, стамеска, тиски, зажим, напильник, фуганок, угломер..., әле аларны күрсәтәм дә. “Алайса рубанок белән эшләп тә күрсәт инде,”- ди. Сизәм, дөрес итеп күрсәтергә кирәк. Зәйнак абый безне аңа бик каты өйрәткән иде. Дөрес итеп бастым, җайлап кына кулымны рубанокка куйдым, тигез генә басып, эшли башладым. Карап-карап торды да: “Укытучыңа рәхмәт әйт, кызларны да шулай зшләргә өйрәткәч, бик яхшы укытучы булган ул,”- диде. Зәйнак абый да укытсын, начар да бел! Теге урындыкларны ул һәр дәрестә тикшерә, 1-3 мм га туры килмәсә, яңадан эшләтә. Наждаклар белән ышкый-ышкый шомартып, чертежга туры китереп, җиренә җиткереп, укытучыга тапшырганда горурлыкның чиге юк. Бишлегә өметләнмибез инде, дүртле булса бездән дә бәхетле кеше юк.

Укыганда Зәйнак абый усал, кырыс, катгый булып тоелса да, үзем укытучы булгач, бу аның таләпчән булуын, тәртипкә өйрәтүен аңладым. Әгәр шундый булмасаң, дәрестә тәртип тә урнаштыра алмыйсың, укучыларга белем дә биреп булмый.

Менә шундый иде безнең УКЫТУЧЫБЫЗ. Гомумән, Зәйнак абый бик тәртипле кеше, эчми, тартмый, кешеләр белән дус яши, гаиләсендә дә тәртип, кулыннан бөтен эш килә. Тормыш иптәше Әнисә апа да бик ачык, мөләем, сабыр кеше. Мин аларның балаларын, оныкларын, хәтта оныкчыкларын да беләм. Барысы да тырыш, ачык күңелле, тәртиплеләр.

ХӨРМӘТЛЕ ЗӘЙНАК АБЫЙ. Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм, сәламәтлек, тыныч тормыш, якты күк йөзе телим. Безне авырлыкларга бирешмәскә, максатка ирешү өчен бөтен көчне биреп

эшләргә, тормышны һәм хезмәтне яратырга өйрәткәнегез өчен сезгә зур рәхмәтләремне белдерәм.

Туган көнегез Җиңү бәйрәме көннәренә туры килә. Иң матур яшьлек елларыгыз авыр сугыш вакытында үткән, сез аннан чыныгып кайткансыз. Җиңү көне белән сезне, Зәйнак абый! Елларга һәм авыруларга бирешмичә, безгә үрнәк булып, яшәгез дә яшәгез әле, кадерле укытучыбыз.

(Әнисә Мәхмүтова)

